ГОРОДСКОЙ СОВЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
ГОРОД НАБЕРЕЖНЫЕ ЧЕЛНЫ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯР ЧАЛЛЫ ШӘҺӘРЕ
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
ШӘҺӘР СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

6 декабрь, 2019 ел № 34/14

Татарстан Республикасы Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 28, 44 статьялары, Татарстан Республикасы Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Уставының 92, 93, 94 статьялары нигезендә

Шәһәр Советы

КАРАР бирде:

1. Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге вәкиллекле органының 2005 елның 8 декабрендәге 6/5 номерлы Карары белән расланган (Шәһәр Советының 2006 елның 19 октябрендәге 15/4, 2007 елның 04 июлендәге 23/4, 2007 елның 25 декабрендәге 28/10, 2008 елның 29 февралендәге 30/7, 2009 елның 09 апрелендәге 40/6, 2009 елның 10 сентябрендәге 42/7, 2010 елның 31 мартындагы 47/7, 2010 елның 27 декабрендәге 7/6, 2011 елның 15 декабрендәге 15/7, 2012 елның 05 июлендәге 19/15, 2012 елның 20 декабрендәге 22/19, 2013 елның 29 августындагы 26/17, 2014 елның 21 февралендәге 29/17, 2014 елның 16 октябрендәге 33/17, 2015 елның 27 февралендәге 38/14, 2015 елның 23 июлендәге 41/11, 2016 елның 24 февралендәге 6/10, 2017 елның 22 февралендәге 15/10, 2017 елның 10 августындагы 18/9, 2017 елның 15 декабрендәге 21/16, 2018 елның 27 апрелендәге 24/8, 2018 елның 11 декабрендәге 28/9, 2019 елның 1 августындагы 32/13 номерлы Карарлары редакциясендә) Татарстан Республикасы Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Уставына түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1) **9 статьяның 1 өлеше 26 пунктында** «документацияне раслау» сүзләреннән соң «шәһәр чикләрендә урнашкан җир участогының шәһәр төзелеше планын бирү» сүзләрен өстәргә;

2) **31 статьяда:**

– **9.1 өлешне** түбәндәге редакциядә бәян итәргә

«9.1. Депутат, җирле үзидарәнең сайланулы органы әгъзасы, җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи заты «Коррупциягә каршы көрәш турында» 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль закондагы чикләүләрне, тыюларны, вазыйфаларны үтәргә тиеш. «Коррупциягә каршы көрәш турында» 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль закон, «Дәүләт вазыйфаларын биләүче затларның һәм башка затларның чыгымнарының аларның керемнәренә туры килүен тикшереп тору турында» 2012 елның 3 декабрендәге 230-ФЗ номерлы Федераль закон, «Аерым категория затларга Россия Федерациясе территориясеннән читтә урнашкан чит ил банкларында счетлар (кертемнәр) ачуны һәм аларга ия булуны, акча средстволары һәм кыйммәтләрне саклауны, чит ил финанс инструментларына ия булуны һәм (яки) аларны куллануны тыю турында» 2013 елның 7 маендагы 79-ФЗ номерлы Федераль закон белән каралган чикләүләрне, тыюларны, вазыйфаларны үтәмәгән очракта, әгәр «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законда башкача каралмаган булса, депутат, җирле үзидарәнең сайланулы органы әгъзасы, җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи заты вәкаләтләре вакытыннан алда туктатыла.»;

- **9.3 өлешендә:**

«җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи заты» сүзләреннән соң «яйсә күрсәтелгән затларга карата башка җаваплылык чараларын куллану» сүзләрен өстәргә;

– түбәндәге эчтәлектәге **икенче-җиденче абзацлар** өстәргә:

«Керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында, шулай ук хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында дөрес булмаган яисә тулы булмаган мәгълүматлар биргән депутатка, җирле үзидарәнең сайланулы органы әгъзасына, җирле үзидарәнең вазыйфаи затына карата, әгәр бу мәгълүматлардагы төгәлсезлекләр әһәмиятле булмаса, түбәндәге җаваплылык чаралары кулланылырга мөмкин:

1) кисәтү;

2) депутатны, җирле үзидарәнең сайланулы органы әгъзасын муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органында, җирле үзидарәнең сайланулы органында вәкаләтләре вакыты туктатылганчы муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органында, җирле үзидарәнең сайланулы органында вазыйфа биләүдән азат итү;

3) даими нигездә вәкаләтләрне гамәлгә ашырудан азат итү, вәкаләтләре вакыты туктатылганчы, вәкаләтләрне гамәлгә ашыру хокукыннан мәхрүм итү;

4) муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органында, җирле үзидарәнең сайланулы органында аның вәкаләтләре срогы

туктатылганчы вазыйфаларны биләүне тыю;

5) вәкаләтләр срогы туктатылганчы даими нигездә вәкаләтләрне үтәүне тыю.

Депутатка, җирле үзидарәнең сайланулы органы әгъзасына, җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи затына әлеге статьяның икенче абзацында күрсәтелгән җаваплылык чараларын куллану турында карар кабул итү тәртибе Татарстан Республикасы Законы нигезендә муниципаль хокукый акт белән билгеләнә.»;

- **11 өлештә** «, шулай ук массакүләм мәгълумат чаралары» сүзләрен төшереп калдырырга;

3) **35 статьяның 1 өлешендә** түбәндәге эчтәлектәге **26 пунктны** өстәргә:

«26) дәүләт серен саклау органнары белән үзара эшчәнлектә:

- башка дәүләт хакимияте органнары, предприятиеләр, учреждениеләр һәм оешмалар тарафыннан тапшырылган дәүләт серен тәшкил итүче белешмәләрне, шулай ук алар тарафыннан яшерен сер булган белешмәләрне саклауны тәэмин итә;

- Россия Федерациясе законнары актлары таләпләре нигезендә җирле үзидарә органнарында дәүләт серен саклауны тәэмин итә, шул исәптән режимлы - яшерен бүлекчә турындагы нигезләмәне раслый;

- дәүләт серен саклау буенча даими нигездә дәүләт серенә рөхсәт бирелгән вазыйфаи затларга һәм җирле үзидарә органнары хезмәткәрләренә бирелә торган социаль гарантияләрнең күләмнәрен билгели;

- дәүләт серенә рөхсәт бирелгән затларга карата үз компетенциясе чикләрендә тикшерү чаралары уздыруны тәэмин итә;

- дәүләт серен тәшкил итүче мәгълүматлардан файдаланган яисә файдалана алган затларның хокукларын чикләү һәм социаль гарантияләр бирү буенча законнарда каралган чараларны гамәлгә ашыра;

- дәүләт хакимиятенең вәкаләтле органнарына дәүләт серен саклау системасын камилләштерү буенча тәкъдимнәр кертә.»;

4) **41 статьяда:**

- «җир участогы» сүзләреннән соң «шәһәр чикләрендә урнашкан» сүзләрен өстәргә;

**7 өлештә**

**2 пунктта** «карар кабул итү» сүзләреннән соң «барлыкка килгән гадәттән тыш хәлләрне муниципаль характердагы гадәттән тыш хәлләр дип билгеләү,» сүзләрен өстәргә;

түбәндәге эчтәлектәге **7.6 пунктын** өстәргә:

«7.6) муниципаль берәмлек территориясендә гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм бетерү буенча гамәлләр планын эшләү һәм раслау;»;

**-11 өлешне** түбәндәге эчтәлектәге **13.1-13.3 пунктлары** белән тулыландырырга:

«13.1) милли һәм җирле социаль-икътисадый, экологик, мәдәни

һәм башка үзенчәлекләрне исәпкә алып, иреклеләргә (волонтерларга) ярдәм итүгә юнәлдерелгән чараларны үз эченә алган муниципаль программаларны (ярдәмче программаларны) формалаштыру һәм тормышка ашыру;

13.2) җирле үзидарә органнарының, муниципаль учреждениеләрнең иреклеләр (волонтерлар) эшчәнлеген оештыручылар, иреклеләр (волонтерлар) оешмалары белән үзара хезмәттәшлек итү тәртибен раслау;

13.3) иреклеләр (волонтерлар) 0эшчәнлеген оештыручыларга, иреклеләр (волонтерлар) оешмаларына, шул исәптән аларның муниципаль учреждениеләр һәм башка оешмалар белән үзара эшчәнлеген тәэмин итүдә, иреклеләргә (волонтерларга), иреклеләр (волонтерлар) эшчәнлеген оештыручыларга, иреклеләр (волонтерлар) оешмаларына мәгълүмати, методик һәм башка ярдәм күрсәтүне тәэмин итүче социаль юнәлешле коммерциянеке булмаган оешмалар. дәүләт һәм муниципаль учреждениеләргә ярдәм күрсәтү;».

5) **74 статьяны** түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1. Муниципаль бурыч - муниципаль бурычка алулардан, өченче зат йөкләмәләре буенча гарантияләрдән барлыкка килә торган йөкләмәләр, РФ Бюджет кодексында билгеләнгән бурыч йөкләмәләре төрләре нигезендә башка йөкләмәләр.

2. Муниципаль бурыч структурасы, муниципаль бурыч йөкләмәләренең төрләре, сроклары, идарә итү тәртибе Россия Федерациясе Бюджет кодексы һәм муниципаль хокукый актлар белән җайга салына.»;

6) **75 статьяда:**

- **4 өлешнең 5 пунктын** көчен югалткан дип танырга;

- **9 өлештә** «һәм гавами тыңлаулар билгели» сүзләрен төшереп калдырырга;

7) **80 статьяны** түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Бюджет средстволарыннан максатчан файдаланмау дип шәһәр бюджеты средстволарын һәм акчалата йөкләмәләрне түләүне бюджет турындагы карар, җыелма бюджет язмасы, бюджет йөкләмәләре лимиты, күрсәтелгән средстволарны бирү өчен нигез булып торучы килешү яки хокукый акт белән билгеләнгән максатларга тулысынча яисә өлешчә юнәлтү атала.»;

8) **81 статьяның 1, 2 өлешләрен** түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1. Бюджет средстволарының баш администраторлары бюджет средстволарын алучылар (күрсәтмә бирүчеләр), бюджет керемнәре администраторлары, бюджет кытлыгын финанслау чыганаклары администраторлары тарафыннан тапшырылган бюджет хисабы нигезендә бюджет хисабын төзиләр.

Җирле бюджетның баш администраторлары бюджет хисабын муниципаль берәмлекнең финанс органына билгеләнгән срокларда тапшыралар.

2. Муниципаль берәмлекнең бюджет хисабы финанс органы тарафыннан бюджет срдстволарының тиешле баш администраторларының бюджет хисаплары нигезендә төзелә.»;

9) **82 статьяның 2 өлешен** түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2. Бюджет үтәлеше турындагы еллык хисап белән бер үк вакытта бюджет һәм бюджет хисабы үтәлешенә анализны һәм муниципаль биремне үтәү турындагы белешмәләр һәм (яисә) бюджет ассигнованиеләрен файдалануның башка нәтиҗәләре турындагы белешмәләрне үз эченә алган аңлатма язуы, бюджет үтәлеше турында карар проекты, шәһәр бюджеты үтәлеше турында башка бюджет хисабы һәм Россия Федерациясенең бюджет законнарында каралган башка документлар тапшырыла.»;

10) **87.1 статьяның 1 өлеше 2 пунктында** «,әгәр федераль законнар белән башкасы каралмаган булса» сүзләрен өстәргә.

2. Әлеге Карар матбугатта рәсми басылган көннән үз көченә керә, нигезләмәләр өчен үз көченә керү гамәлдәге законнар белән башка вакытта каралган.

3. Яр Чаллы шәһәре Хакиме Н.Г. Мәһдиевка әлеге Карарны гамәлдәге законнарда билгеләнгән тәртиптә дәүләт теркәвенә тапшырырга.

4. Әлеге Карар үтәлешен контрольдә тотуны Шәһәр Советының регламент, хокук тәртибе һәм халык иминлеген тәэмин итү мәсьәләләре буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Шәһәр Хакиме Н.Г. Мәһдиев

Городской Совет муниципального образования город Набережные Челны Республики Татарстан · Татарстан Республикасы Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге шәһәр Советы · ПРОТОКОЛЬНАЯ ЧАСТЬ · БЕРКЕТМӘ БҮЛЕГЕ

Россия Федерациясе Юстиция министрлыгының Татарстан Республикасы буенча идарәсе тарафыннан 2019 елның 18 декабрендә теркәлде. Дәүләт теркәве номеры RU 163020002019002